
Бүгенге санда:



**ПЕЧӘН ӨСТЕ: азык күләмле дә, сыйфатлы да булсын. 2 бит**


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 5 июнь 2015 ел

№ 41 (10570)


**6 июньгә һава торышы:** аз болытлы һава, урыны белән яңгыр, җил төньяк-көнчыгыштан 5-7 м/с; температура көндез +18°С, төнлә +11°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### УКУЧЫЛАР АЛЛЕЯ САЛА

Шикәрчеләр бистәсендә Дан аллеясы утыртылды. Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан Завод урамы буенча әлеге аллеяга шәһәрнең 3нче мәктәбе укучылары нигез салды. 70 миләш һәм сирень үсентеләреннән торган аллеяны утыртуда 6а, 6б, 7б сыйныфы укучылары аерата актив булдылар. Ә үсентеләрне исә эти-әниләре һәм әби-бабайлары белән берлектә 5б сыйныф укучылары әзерләде.

### ШОФЕРЛАР ЯРЫШТЫ

Нурлат технологик транспорт идарәсе командасы "Татспецтранспорт" компаниясе Спартакиадасы кысаларында уздырылган мини-футбол буенча ярышлардан II урын алып кайтты. Әлеге турнир 30 майда Алабугада үтте.

### МИЛЛИОНЕР БАКЧА

"Чишмәкәй" балалар бакчасы 1 миллионлык грантка ия булды. Шул көннәрдә районда "Иң яхшы билингваль балалар бакчасы" республика конкурсына йомгак ясалды. Конкурста быел районнан Урта Камышлы һәм "Чишмәкәй" балалар бакчалары катнашты. Нәтиҗәдә, "Чишмәкәй" балалар бакчасы җиңү яулады.

### БИТАРАФ БУЛМАГЫЗ!

Нурлат районы территориясендә легаль булмаган алкоголь продукциясе сату фактлары турындагы хәбәрләрне **02, 2-11-25** (Россия МВДсының Нурлат районы бүлеге), **2-19-45** (ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Чистай территориаль органы) телефоннары буенча җиткерергә мөмкин.

# Рөстәм Миннеханов: "Иң мөһиме – барлык дәрәҗәдәге хакимият гамәлләренең бердәмлеге"



Фото Татарстан Президентының рәсми сайтыннан

**30 майда Татарстанның заманча тарихында парламентаризм оешуның 25 еллыгына багышлап республиканың барлык чакырылыш депутатлары һәм җәмәгатьчелегенең тантаналы җыелышы үтте.**

Татарстан Президенты нәкъ менә 25 ел элек булган язмышыбызны билгеләүче вакыйга барлык бүгенге казанышларыбыз һәм уңышларыбызның нигезен тәшкил итә, дип билгеләп үтте. Татарстанда законлылык һәм башкарма хакимиятнең конструктив диалогы көйләнде, бу алга таба үсүне тәэмин итә. "Без Татарстанның Россия чикләрендә дә танылу алуы белән чын-чынлап горурлана алабыз, – диде Рөстәм Миннеханов. – Безне югары икътисадый үсеш темпы, иҗтимагый-сәяси тотрыклылык, тарихи-мәдәни мираска сакчыл карашыбыз, рухилыгыбызның үсеше һәм киң кунакчыллыгыбыз өчен хөрмәт итәләр. Республиканың халыкара киңлектә танылуы инвестицияләр җәлеп итү, иң перспектив проектларны гамәлгә ашыру өчен дә яңа мөмкинлекләр тудыра".

**Бу турыда тулырак "Атна вакыйгалары"нда укыгыз.**

## САБАНТУЙ СЕЗНЕ КӨТӘ!

**ИРТӘГӘ, 6 ИЮНЬДӘ НУРЛАТТА ХАЛКЫБЫЗНЫҢ МИЛЛИ БӘЙРӘМЕ – САБАН ТУЕ. ПРОГРАММАДА – ТРАДИЦИОН АТ ЧАБЫШЛАРЫ, МИЛЛИ КӨРӘШ, КҮПЛӘГӘН УЕННАР, ҖЫР-БИЮ, КҮҢЕЛ АЧУ ЧАРАЛАРЫ. БӘЙРӘМНЕ ТАНТАНАЛЫ АЧУ 10.00га БИЛГЕЛӘНГӘН.**

КӨН ТЕМАСЫ

# Җәен мотоцикл-скутерлар бәласе калка

**Җәйге каникуллар чорында балалар иминлеге әти-әниләрне генә түгел, республика, район җитәкчелеген дә борчый.**

3 июньдә узган юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча хөкүмәт комиссиясенең чираттан тыш утырышы да балалар иминлегенә багышланган иде.

Каникуллар башлану белән район һәм шәһәр юлларында балигъ булмаган мотоциклчылар, скутерчылар күренә башлады. Бу уңайдан ЮХИДИ бүлеге хезмәткәрләре борчылып чаң суга. Мотоцикл һәм скутерлар – бик куркыныч транспорт чаралары, еш кына алар үз хуҗаларын гына түгел, җәяүлеләрнең дә үлеменә сәбәп була, диләр юл инспекторлары. Мисал өчен, 3 июньдә Түбән Нурлат микрорайонында килеп чыккан юл-транспорт һәлакәтендә дә исерек, өстәвенә "права"-сыннан мәхрүм ителгән мотоцикл хуҗасы 5 яшьлек велосипедчы баланы бәрдерә. Фаҗига 21.20 сәгатьтә теркәлә. Мотоцикл хуҗасы караңгы урамнан ялгызы гына хәрәкәтләнүче һәм яктылык сирпүче киеме булмаган баланы күрми. Бәхеткә, балага зыян килми. Хәзер әлеге ситуация уңаеннан тикшерү дәвам итә.

– Узган ел район юлларында мотоциклчылар катнашында 3 юл-транспорт һәлакәте теркәлде, – ди ЮХИДИ бүлеге начальнигы Рөстәм Гарипов. – 2 кеше үлде, 2се төрле тән җәрәхәтләре алды. Мотоциклчы һәм скутерчыларның иминлеге күпчелек очракта экипировкадан тора. Һәм киемнәрнең яктылык чәчә торган элементлардан торуы шарт. Нигездә, әлеге транспорт хуҗалары шлемнар кулланмый. Ә бит һәлакәтләрнең 65 процентында баш миенә зыян килә, 38 процентта бу үлемгә сәбәп булып тора.

Юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре нигезендә, мотоцикл руле артына 18 яшьтән һәм ЮХИДИ бүлегенә имтихан тапшырып, "А" категорияле таныклык алганнан соң гына утырырга мөмкин. Скутер белән идарә итү өчен дә 16 яшь тулган булырга тиеш. Үсмер 16 яшь тулмаган көе скутер руле артына утыра икән, моның өчен эти-әниләре җаваплылыкка тартылачак.

Зилия ӘКСАНОВА

## САН

**2014 елда районда юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозган өчен 36 мотоцикл махсус штраф стоянкасына ябылган. Узган ел әлеге транспорт катнашында 3 юл-транспорт һәлакәте теркәлгән. Агымдагы елның 5 аенда 1 юл-транспорт һәлакәте чыккан, 10 транспорт махсус стоянкага ябылган.**

# ВӘЗГЫЯТЬ

ИҖАТ

## “Йолдызлык” талантлар үстерә

**“Созвездие – Йолдызлык” эстрада сәнгатенең XV ачык телевизион яшьләр фестиваленең финал турында быел районнан 17 сәләтле бала катнашты.**

Бәйге ел саен республика лидеры Рөстәм Миннехановның теләктәшлеге белән оештырыла, һәм ул быел Җиңүнең 70 еллыгына багышланды. Беренче елларда шәһәр бәйгесе буларак кына үткәрелгән әлеге эстрада сәнгате конкурсы бүген киң колач җәеп, Россия дәрәҗәсендәге хәрәкәткә әверелде. Рөстәм Миннеханов талантларны яклауга зур игътибар бирә. Билгеле, Нурлат балалары да бу иҗади бәйгедән читтә калмый.

– Районыбызда сәләтле балалар бик күп, – ди “Калейдоскоп” миниатюралар театры коллективының сәнгать җитәкчесе, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Валентина Голубева. – Президентыбыз патронатында узучы әлеге фестиваль нәкъ менә сәләтле балаларны ачыкларга һәм аларны иҗади яктан үстерергә, яңа талантларны ачарга ярдәм итә.

Нурлатның яшь артистлары да 13 апрельдә “УНИКС” комплексында узган фестиваль суперфиналының сайлап алу турында “Вокал” һәм “Конферанс” номинацияләрендә чыгыш ясадылар. Суперфиналда шәһәрнең 3нче урта мәктәбе укучысы Екатерина Снегурова һәм “Калейдоскоп” миниатюралар халык театры коллективы Нурлат данын якладылар.

2008 елда оешкан “Калейдоскоп” миниатюралар театрына нигез салучы һәм аның сәнгать җитәкчесе – Валентина Голубева. Җиде ел эчендә нурлатлылар әлеге иҗади коллективның чыгышларын яратырга өлгерде инде. Бүген театрның “Балалар конферансы” бүлеге театр сәнгатен яратучы 8 баланы берләштерә. Алар катнашыннан башка районда бер генә мәдәни-масса чарасы да узмый. Коллектив 5 ел рәттән “Созвездие – Йолдызлык” фестивалендә катнашып, лауреат һәм дипломант исемнәренә лаек булып килә. 3 ел рәттән суперфиналда чыгыш ясадылар. Театрның яшь артистлары – Кирилл Захаров, Диләрә Хәсәншина, Игорь Тимофеев, Ольга Рыскина, Настя Лобашованың чыгышлары нурлатлыларның гына түгел, Татарстан тамашачыларының да алкышларына күмелде. Ә Игорь Тимофеев 2013 елда республикада II урынны яулаган иде.

2013 елда Нурлатта узган зона турында гына да районыбызның 200 яшь таланты чыгыш ясады. Аларның унысы фестивальнең 3нче турына узды. Чыгышларга бәя биргән мәртәбәле жюри – ТР һәм Россиянең халык артисткасы Зилә Сөнгатуллина, фестивальнең генераль продюссеры Дмитрий Туманов, ТРның халык артисты Мөнир Соколов, республиканың җыр һәм бию Дәүләт ансамбленең баш балетмейстеры Раилә Гарипова Нурлат җирендә талантлы балаларның күп булуын билгеләп узганнар иде.

Шунысын да әйтми булмый: “Йолдызлык” фестиваль хәрәкәте яшь нурлатлылар өчен үзенә күрә иҗади Олимпка трамплин да әле ул. Әнә, балалар сәнгать мәктәбе чыгарылышлары – Искәндәр Гайсин, Рөстәм Насыйбуллин да әлеге фестивальдә катнашкан егетләр. Бүген алар үз тормышларын сәхнә белән бәйләп, музыка колледжында, Казан дәүләт консерваториясендә белем алалар. Шәһәрнең 3нче урта мәктәбе һәм Балалар сәнгать мәктәбе чыгарылышы, “Сөембикә варислары” халыкара конкурсы, “Созвездие – Йолдызлык” фестивале лауреаты, “Татар моңы” телевизион халыкара фестивале дипломанты Гүзәл Әхмәдиева Казан музыка колледжын тәмамлап, КФУ һәм Казан дәүләт консерваториясендә белемен арттыра.

**Ел саен фестивальдә 70 меңнән артык сәләтле бала һәм яшьләр катнаша. Фестиваль гала-концертының телевизион аудиториясе - 41 миллионлап тамашачы.**

– Балалар сәнгать мәктәбе коллективы мондый дәрәҗәле конкурс-фестивальләрне күз угыннан ычкындырмый, – ди мәктәп директоры Валентина Тяжова. – 15 ел рәттән үткәрелүче бәйгедә безнең мәктәп укучылары төрле номинацияләрдә чыгыш ясый. “Вдохновение”, “Кнопочки”, “Әйлән-бәйлән”, “Элегия”, “Радуга” ансамбльләре һәм “Дети Солнца” хореография төркеме матур уңышлары белән сөендерделәр. Моннан тыш, Диләрә Хәсәншина, Алина Ларионова, Гөлназ Шәйхетдинова, Айгөл Әфләтунова, Дмитрий Николаев кебек сәләтле укучыларыбыз да – әлеге мәртәбәле фестиваль дипломантлары һәм призерлары. Кыскасы, Роза Әхмәтҗанова, Ольга Гришина һәм Динара Хәсәнова шәкертләре елның-елында “Йолдызлык”та чыгыш ясап матур уңышларга ирешәләр. Шундый дәрәҗәле фестиваль мәктәбебезнең сәләтле укучыларына үз талантларын үстерергә ярдәм итә. Финал этапларында жюри әгъзаларының, фестиваль кунаклары – сәнгать әһелләренең чыгыш ясаучылар белән түгәрәк өстәлләр, мастер-класслар үткәрүе үзе зур нәрсә. Алар балаларга иҗади яктан камилләшергә булыша.

Кыскасы, “Йолдызлык” – киләчәктә нәни талантларга олы иҗат юлы ача, балаларда сәнгатькә мәхәббәт тәрбияли торган кабатланмас һәм уңышлы иҗади проект.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## Малга – азык, хуҗалыкка – керем

ПЕЧӘН ӨСТЕ

**Район хуҗалыклары бердәм булып печәнгә төштеләр.**

“Нурлат сөте” хуҗалыгы Иске Чаллы бүлекчәсенең 160 гектарлы люцерна басуына дым да, өстәмә сый да, игътибар да җиткән быел. Ямь-яшел куе үлән арасында чүп үләннәре дә, сары тузганак чәчәкләре дә күренми, вакытында һәм барлык таләпләренә туры китереп җыеп алганда, кышын маллар өчен менә дигән кыйммәтле азык булачак. Сишәмбе көнне шул басу янәшәсенә бер рәткә тигез итеп тезеп куелган азык әзерләү техникасын караганнан соң, республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы вәкилләре дә бу басуга югары бәя бирделәр.

– Районда гына түгел, республикада да мондый басулар сирәк, агрономнар һәм механизаторларның һөнәрмәнлеге нәтиҗәсе бу, - ди министрлыкның фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлеге начальнигы Наил Хәмидуллин. – Бүген районның барлык хуҗалыкларында да булып, азык әзерләү техникасының һәм азык саклау урыннарының әзерлеген карап чыктык һәм Нурлатта җыярга азык та, аны җыю өчен техника да бар, дигән нәтиҗәгә килдек.

Министрлык вәкилләре районның азык җыюга әзерлеген республика смотр-конкурсы кысаларында тикшерделәр. Республикада азык әзерләү – урак кебек үк җаваплы кампания, һәм аның барышы шулай ук җитди игътибар астында. Өстәвенә, быел мал асраучыларның күбесе язга азык запасын бетереп диярлек чыктылар.

– Бер баш терлеккә 35 центнер бирәмлек исәбеннән азык әзерләүне күздә тотабыз, - ди районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. – Әмма азыкның күләмле генә түгел, аның сыйфатлы булуы да мөһим. Соңгы видеокиңәшмәләрнең берсендә министрыбыз Марат Әхмәтов та шундый бурыч куйды. Ә азык сыйфатлы булсын өчен барыннан да бигрәк күпьеллыкларны яңартып тору кирәк.

Быел районда күпьеллыкларның 30 процентлабы яңартылган икән. “Нурлат сөте”ндә ул - 200 гектар. Бүгенге көндә 5600 баш мөгезле эре терлеге булган хуҗалык өчен җитәрлек азык әзерләп калу аеруча актуаль.

– Печән әзерләүгә узган атнада ук керешкән идек, бер эскерт әзер инде. Шөкер, май ае яңгырлы булгач, үләннәр дә гөрләп үсә, - ди хуҗалык җитәкчесе Вәзир Сәгыйров. – Һәр 4 бүлекчәдә азык әзерләү бригадалары булдырылды, бурычлар билгеләнде. Техника да, кешеләребез дә җитәрлек. Азык культураларының мәйданнары да хуҗалык терлекләренә җитәрлек азык туплап калырга мөмкинлек бирә. Күпьелыклар һәм кукуруз 1500әр, берьеллык үләннәр һәм үлән катнашмалары 1200ләп гектарда бездә.



“НУРЛАТ СӨТЕ”НЕҢ ЛЮЦЕРНА БАСУЫ ҮЛӘННӘРНЕҢ КУЕЛЫГЫ БЕЛӘН АЕРЫЛЫП ТОРА.

Район буенча исә үләннәрне беренче катка чаптыруны ике сменада оештырып, 15 июньгә кадәр төгәлләү бурыч итеп куела.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

### САН

**Район буенча быел күпьеллыклар 8260, кукуруз 4500, берьеллык үләннәр 4000 гектар тәшкил итә.**

### ХӘБӘРЛӘР

## ИЛБАШЫ КОТЛАВЫ

**Шул көннәрдә тыл хезмәтчәне Ольга Зайцева 90 яшьлек гомер бәйрәме уңаеннан РФ Президенты Владимир Путинның хатын, район башлыгы Равил Кузюров исеменнән котлау һәм бүләк кабул итте.**

Юбилярны район җитәкчелеге исеменнән район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова һәм “Гармония” үзәге директоры Елена Пичушкина тәбрикләделәр. Ольга Ивановна Нурлат районының Осиновка поселогында туган, 50 ел шунда колхозда эшләгән. Бөек Ватан сугышы башланганда аңа 16 яшь була. “Бик авыр иде. Фронт өчен агач, бөртек ташыдык. 8 ел урманда эшләдем”, – дип искә ала Ольга Ивановна. Ольга Зайцева инде 40 ел улының гаиләсе белән Нурлатта яши. 3 оныгы һәм 5 оныкчыгы бар.

**Гөлназ ГАЗИЗОВА**

## ӨЙРӘНҮНЕҢ КИРӘГЕ ЧЫКМАСЫН

**Район эвакокабул итү комиссиясенең чираттагы утырышында өч мәсьәлә каралды.**

Районның гражданнар оборонасы системасының халыкны кабул итү, урнаштыру буенча әзерлеге турында район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова чыгыш ясады. “Әле февраль аенда гына районыбыз гадәттән тыш хәлләргә әзерлек буенча имтихан тотты. Бу эш районда яхшы оештырылган, әмма әзерлек тренировкалар өчен генә кулланылсын иде”, - диде Флюра Рәшитовна. Комиссия утырышларында район һәм шәһәр эвакуацион комиссияләре эше турындагы мәгълүматлар да тыңлана. Алдагы утырышларда Тәрнәс, Егоркино пунктлары начальниклары хисап тотса, бу юлы Киекле пункты иде. 4нче эвакуацион пункт начальнигы, Киекле урта мәктәбе директоры Гүзәлия Абдрахманова әйтүенчә, мәктәп бинасында урнашкан пунктта барлыгы 46 кеше эшли, һәм алар Бөгелмәдән 10576 кешене кабул итә ала. Февраль аенда узган штаб өйрәнү тренировкаларында бу эвакуацион пункт эше “бик яхшы”га бәяләнгән. Бер ай элек районның эвакокабул итү комиссиясе Бөгелмә МЧСы белән берлектә уртак киңәшмә уздырган. Анда актлар төзелгән, эвакуацияләнүче оешмалар белән продуктлар, медикаментлар китерүгә һәм биналар арендалауга килешүләр төзелгән. Гражданлык оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге әйдәп баручы консультанты Фәридә Борһанова гражданлык оборонасына кагылышлы законнарга үзгәрешләр кертелү турында сөйләде. Комиссия эшендә катнашкан 125нче янгын часте начальнигы Илһам Курамшин бу өлкәдә һәрвакыт әзерлек кирәк булуын ассызыклады. Соңыннан штаб тренировкаларында актив катнашучыларга район башлыгының Мактау грамоталары тапшырылды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## ТАККЫЧЛАР ТИКШЕРЕЛӘ

**Гостехнадзорның Нурлат районы һәм шәһәре бүлеге 8 июньнән “Трактор – Таккыч” профилактик операциясенә кушыла.**

30 июньгә кадәр дәвам итәчәк профилактик операция үзйөрешле машиналар һәм таккычлар катнашындагы хокук бозулар һәм юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтү максатыннан үткәрелә.

– Бу чорда үзйөрешле техника һәм таккычларның техник торышы файдалану вакытында тикшереләчк, - ди бүлекнең баш дәүләт инженер-инспекторы Дмитрий Кудряшов. – Шулай ук эксплуатацияләүгә рөхсәт кәгазьләре, теркәү документлары, дәүләт теркәү билгеләренең булуы һәм дөрес урнаштырылуына, йөртүченең тиешле таныклыгы булуына аерым игътибар биреләчәк.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

## КӨН АРТЫННАН КӨН

“НУРЛАТНЕФТЬ” НГДУсында

# Беренчелеккә омтылу – уңыш нигезе

**Узган шимбә көнне “Нурлатнефть” НГДУсының яшь хезмәткәрләре арасындагы традицион һөнәри осталык конкурсы үтте.**

Гадәттәгечә, нефтьчеләр үз белемнәрен һәм күнекмәләрен “ЦПК-Татнефть”нең Нурлат филиалындагы өйрәнү-тренировка мәйданчыкларында күрсәттеләр.

Иң элек конкурста катнашучыларны – вахталар, звенолар, аерым эшче һөнәрләр вәкилләрен Нурлат районы башкарма комитеты җитәкчесе Әсхәт Габдуллин сәламләде. Ул бу конкурсны эшче һөнәрләр чемпионаты белән чагыштырды, әлеге бәйге май аенда Казанда узган һәм Әсхәт Касыймович та анда булып кайткан иде.

– Соңгы елларда аерым төр эшче һөнәрләр турында онытa башладылар. Әмма хәзер яшьләр моңа тартыла – эретеп ябыштыручы, пешекче һәм башка төр юнәлешләрне сайлыйлар. Бүген бездә дә шундыйрак чемпионат уза, биредә сез белгән күнекмәләрегезне күрсәтәчәксез. Барыгызга да уңышлар юлдаш булсын. Бу чара бик кирәкле, җитәкчелек һәм инженерлык составы иң яхшы хезмәткәрләрен якыннанрак белә алачак, – диде ул һәм нефтьчеләрнең район тормышындагы рольләрен дә билгеләп үтте. – Кичә “Нурлатнефть” коллективы тырышлыгы белән “Чияле Алан” сәламәтләндерү комплексының яңа корпусын ачтык.

Баш инженер-“Нурлатнефть” НГДУсы начальнигының производство буенча урынбасары Равил Әхмәдиев бу көнне бәйрәм дип атады.

– Яшь хезмәткәрләр полигонда җыелып, үз осталыкларын, һөнәрмәнлекләрен күрсәтәләр. Мин сезгә бүген тупланган булуыгызны, нәтиҗәле чыгыш ясавыгызны телим. Беренче булырга омтылыгыз, – диде ул.

Баш инженер сүзләренә караганда, конкурс кагыйдәләре элеккеге кебек үк калган, бары тик яшь чикләүләренә карап, катнашучылар составы гына үзгәргән – бәйгедә 33 яшькә кадәрге хезмәткәрләр ярыша. Равил Нурович әйткәнчә, шул рәвешле коллектив предприятиенең күп еллар элек салынган традицияләрен саклап калачак.

Һәм менә мөһим мизгел. Составында Илнур Ибраһимов һәм Роберт Ярушкин булган нефть әзерләү һәм кудыру звеносы флагштокка атлыйлар, һәм, конкурска старт сигналы биргәндәй, полигон өстендә предприятие әләме җилферди башлый. Катнашучылар үз урыннарына таралышалар.

Конкурс гамәли һәм теоретик биремнәрдән торды. Мисал өчен, нефть һәм газ чыгару звенолары гамәли өлештә сальник утырту һәм прокладка алыштыру кебек биремнәр башкардылар. Аннан соң компьютер классында теория буенча сорауларга җаваплар бирделәр. Ярышларның бу өлеше дә гамәлие кебек үк бик мөһим булып чыкты. Мәсәлән, гамәли өлеш буенча лидер 3нче ЦДНГ иде. Ике бирем буенча алар башкалардан күбрәк баллар туплый алдылар. 1нче ЦДНГ 2 баллга калыша иде, әмма теорияне шәп белү аларны лидерлыкка чыгарды.

ЦКППН һөнәри осталык конкурсына 3 команда куйды: берсе – тәҗрибәле, мондый ярышларда икенче ел катнаша инде, калган ике командалары яңалар иде.

– Катнашучылар конкурска ике айдан артыграк әзерләнделәр, – ди цех начальнигы Сергей Рафиков. Бу катнашучыларның үз традицияләре дә бар икән – биремнәрне үтәүләрен баш инженер тикшерә.

Электр белән эретеп ябыштыручылар участогында аерата кызу иде. Сигез катнашучы 6 этапта көч сынаша – җыю, эретеп ябыштыру, теория... Электр белән эретеп ябыштыручылар гамәли өлештә 159 мм диаметрлы 8 мм калынлыктагы торбадан вакытка катушка ябыштыруда ярыштылар. Ә җыю һәм ябыштыру җөен дефектоскопистлар тикшерә.

Һөнәри осталык конкурсы, чыннан да, бәйрәмне хәтерләтте. Катнашучылар ярышкан арада өйрәтү-тренировка мәйданчыкларында җирле үзешчәннәр җырларын яңгыратты, хуплау төркемнәре дә тавышларын кызганмадылар.

Бу чара бер тында үтте, вакыт сизелмәде дә. Һәм менә нәтиҗәләр чыгарыр мизгелләр дә җитте. Нефть һәм газ чыгару звенолары арасында I урынны мастер Арслан Хәмидуллин звеносы алды (1нче ЦДНГ), ППДлар арасында I урын мастер Фәрит Дәүләтшин звеносында, химик анализ лаборантлары арасында иң яхшысы дип Мария Зайцева табылды. ПРС вахталары ярышында лидерлык мастер Илшат Шәйдуллин звеносында булды, нефть әзерләү сменалары арасында I урынны Илнур Ибраһимов белән Роберт Ярушкин сменалары алды. Электр-газ белән эретеп ябыштыручылар арасында беренчелекне берничә ел рәттән инде Илдар Әһлиуллин яулап килә, быел да ул җиңде. Илдар остаз булып алырга да өлгерде, конкурска Линар Мотыйгуллинны әзерләгән. Ул нефтьчеләр коллективына әле быелның февралендә генә килеп кушылса да, конкурста II урынга чыкты. Иң яшь катнашучы – су һәм тоз кудыру җайланмасы операторы Фәндәс Әхмәтовны да истәлекле бүләк белән билгеләп үттеләр. Спорт ярышлары да бик кызыклы үтте: биредә аркан тартышу, армрестлинг, шашка, шахмат, пневматик мылтыктан атуда көч сынаштылар. Аркан тартышуда ЦТРС командасына тиңнәр булмады. Шулай булмыйни, Андрей Стабровский белән Илнур Сәйфетдинов аркан тартышу буенча “Татнефть” ААҖнең җыелма командасы составына да кертелгәннәр бит. Әтиләренә көч биреп торырга килгән яшь җанатарлар да игътибарсыз калмадылар, аларга татлы бүләкләр өләшенде. Ә предприятие әләмен төшерү хокукы I урын алган 1нче ЦДНГның нефть һәм газ чыгару звеносына бирелде.


Автор фотосы

ҖИҢҮЧЕЛӘРНЕ ТАНТАНАЛЫ КОТЛАУ МИЗГЕЛЛӘРЕ

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

*Реклама хокукында*

ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ БЕЗ

# Нурлатка экодесант төште

**Шул көннәрдә тәмамланган Татарстандагы санитар-экологик икеайлык барлык рекордларны бәрде. Бу атнада аңа нәтиҗәләр ясалды.**

Республиканың экология һәм табигый ресурслар министры Артем Сидоров билгеләп үткәнчә, тулаем алганда, барысы да яхшы эшләгән. Шул еллар эчендә беренче тапкыр бер генә район да кискен тәнкыйтькә эләкмәгән. Нурлатлыларның хезмәте дә мактауга лаек. 1 апрельдән 31 майгача шәһәр һәм район халкы үз ишегалларын гына түгел, ә якын-тирә территорияләрне дә тәртипкә китерделәр, парк, скверларны, балалар мәйданчыкларын чүп-чардан арындырдылар, газоннар, чәчәклекләр төзекләндерелде, агач-куаклар утыртылды. Массакүләм өмәләрдә 6300дән артык кеше катнашты. Болар – предприятие-оешма хезмәткәрләре, иҗтимагый хәрәкәтләр, депутатлык корпуслары вәкилләре, волонтерлар, укучылар, экологик актив, шулай ук битараф булмаган кешеләр. Ике ай эчендә каты көнкүреш калдыклары полигонына һәм махсус урыннарга гына да 11370 куб метр чүп-чар чыгарылды. Өмәләргә 1484 берәмлек техника җәлеп ителде. 16 яңа контейнер мәйданчыгы төзелде. Ключи микрорайонындагы 700 квадрат мәйданлы санкцияләнмәгән чүплек бетерелде, районда 6650 агач һәм 1377 куак утыртылды. Шул ук вакытта, административ комиссия икеайлык барышында 78 кагыйдә бозуны ачыклады һәм аларның барысы да диярлек төзәтелгән. Төзекләндерү кагыйдәләрен бозган өчен күзәтчелек органнарының игътибарына вазифаи затлар, гадәти гражданнар белән беррәттән, эшмәкәрләр дә эләкте.

– Без 70 беркетмә төзедек, 42 граждани, 4 вазифаи һәм 1 юридик зат административ җаваплылыкка тартылды. Җәмгысе 344 мең сум штраф салынды, – дип икеайлык нәтиҗәләре белән таныштыра административ комиссия секретаре Вера Мальцева.

Чагыштыру өчен: икеайлык барышында штрафлар суммасы Татарстан буенча 26 млн. 529,5 мең сум тәшкил иткән. Министр Артем Сидоров сүзләренә караганда, мондый алым да һәрчак нәтиҗәсен бирми икән. Ул чүп пакетларын тиешле булмаган урыннарга ташлаучыларга, шулай ук ишегалларында чүплек ясаучыларга каршы көрәшергә чакыра. “Кагыйдә бозулар өчен физик затларга җаваплылыкны көчәйтү турында инициатива әзерләячәкбез”, – диде ул сишәмбе көнне узган брифингта.

Икеайлык рәсми рәвештә тәгәлләнде, әмма бу юнәлештә эшләр дәвам итә.

– Сүз дә юк, күп эшләр башкарылды, әмма аерым игътибар таләп итүче объектлар бар әле. Чөнки шәһәр һәм авыл хуҗалыкларын тәртиптә тоту өчен моны ел дәвамында кайгырту зарур, – ди районның баш экологы Рөстәм Ногманов һәм сүзләрен конкрет гамәлләр белән җөпли. – Бүген, Бөтендөнья әйләнә-тирә мохитне саклау көнендә шәһәрдә “Будетчисто” волонтерлык экологик хәрәкәте активистлары катнашында Октябрьнең 40 еллыгы урамында яшьләр форматында массакүләм өмә узачак.

**Маргарита ЛИТТА**

## САНДУГАЧЛАР САНАРГА ЧАКЫРАБЫЗ

**“Сандугачлы кичләр”– Россиядә 1998 елдан бирле барган сандугачларны исәпкә алу табигатьне саклау акциясе шундый матур исем белән атала.**

Мәскәүдә нигез салынган әлеге акциягә хәзер инде илнең 30лап эре шәһәре, шул исәптән икенче ел Казан да кушыла. Бу– үзенә күрә әйләнә-тирә мохитның торышы индикаторы һәм халыкның игътибарын кошларны саклауга юнәлтү чарасы да. Гадәттә ул майның 20ләреннән башлана һәм июнь ахырына кадәр бара. Ә бит сандугачлар Нурлатта һәм Нурлат районында да сайрый, бездә андый акциягә кушылу күздә тотылмый микән?

– Бик рәхәтләнеп,–диде безнең тәкъдимгә кушылырга ризалашып шәһәрнең 3нче мәктәбе география укытучысы, “Мәктәп урманчылыгы” җитәкчесе Татьяна Чибидина.–Узган шимбә көнне үзем дә туган авылым Сәләнгештә сандугачлар сайравына бихуш булып кайттым.

Димәк, районцашлар, сандугачлар санарга керешәбез! “Сандугачлы кичләр”дә катнашырга теләүчеләр кошлар сайраган урынны күрсәтеп, үз фамилияләрен дә язып, мәгълүматны tchibidinat@mail.ru адресына юллый алалар. Әлеге тема турында киңрәк мәгълүмат алырга теләүчеләргә Вконтакте һәм Facebook төркемнәренә түбәндәге адрес буенча керергә мөмкин: http://vk.com/tatarstanSOPR, https://www.facebook.com/arininaalla. Веб-сайт: http://www.rbcu.ru/ Ә сандугач сайравын өйдә дә тыңларга мөмкин. http://www.youtube.com/watch?v=DzsLHCFyFdw адресы буенча Мәскәүнең Ботаника бакчасында 2014 елның 21 маенда төшерелгән сандугач хорын ишетеп хозурланырсыз.

## СУ ИСӘПСЕЗ ТҮГЕЛ

**Шәһәрнең 3нче мәктәбендә “Су саклаучылар” Бөтенроссия акциясендә катнаштылар.**

Планетаның 75 процентын су алып торса да, чиста су проблемасы көннән-көн кискенләшә бара. Укучылар Бөтенроссия акциясенең шул җитди проблеманы кузгату җәһәтеннән уздырылуын бик яхшы аңладылар һәм аңа теләп кушылдылар.

Сезнең гаиләдә аена күпме су сарыф ителә, бу җан башына күпмегә төшә?Укучылар тиз арада санап та алдылар: уртача су сарыфы җан башына 1,9 куб. метр икән. Аннан соң командалар “Суны ничек тотарга ярамый” дигән темага зыянлы киңәшләр уйлап көч сынаштылар. Плакатлар бик тә тәэсирле килеп чыкты.Соңыннан әлеге материалларны Россия сайтына салдылар, үзләренең Чирмешән һәм Кондырча ярларын чистарту буенча алып барган эшчәнлекләре турында язарга да онытмадылар. Балаларның су саклаучылар сафына басуы – иртәгәге көнебез турында олыларча уйларга сәләтле булуларына дәлил ләбаса!

**Сәкинә НУРУЛЛИНА**

МАНЗАРА

# “ТЯМАЕВ-ФЕСТ”: яңа бәйрәмгә нигез салынды

**Түбән Нурлат микрорайонында “Тямаевфест” бәйрәме үтә дигән хәбәр нурлатлыларны гына түгел, республика районнарында, Самара, Ульян өлкәләрендә яшәүче җыр-моң сөючеләрне үзенә җыйды. Һәм үкенерлек тә булмады: бәйрәм республиканың дистәдән артык җырчысы чыгышына милли Сабантуебыз элементларын да өстәп, гаҗәеп зур һәм истә калырлык халык күңел ачу чарасы булып узды.**

Ни өчен “Тямаевфест”? Күптөрле халык бәйрәмнәре арасында заманча яңгырашы белән аерылып торган исемнең үз расшифровкасы бик гади иде: ”Фирдүс егетләре сәхнә тота”. Чөнки бәйрәмне үткәрү мәшәкатьләрен якташыбыз–халкыбызның яраткан автор-башкаручысы, өч тапкыр “Алтын Барс” премиясе лауреаты Фирдүс Тямаев үз өстенә алды, иҗатташлары, дуслары аны берсүзсез күтәрештеләр.

Бәйрәм үткәрәм, дип әйтү генә җиңел икән. Фирдүс үз егетләре белән әзерлек эшләрен әрәмәлекне чистарту, күперләрне төзекләндерү, мәйданны җиһазлаудан башлады. Ә ике көн кала Сабантуй алдыннан була торган күмәк чара–бүләк җыю үткәреп, халык күңеленә бәйрәм кытыгы салып чыктылар.

– Халык үзе теләде бүләк тапшырырга,–ди Фирдүс. Шулайдыр, чөнки һәр йорт тукталышында җыр-бию, рәхмәт әйтү, сөенечтән балкыган йөзләр бәйрәмнең тансыклыгын сиздереп торды.

– 19 ел элек булган иде бездә Сабантуй, быел Фирдүс бәйрәм оештыра дигәч, Мәскәүдән үк кайттым,–диде Флюра Сәйфетдинова. Хәер, мәйданда махсус бәйрәмгә дип кайтучылар бер ул гына түгел иде. “Тямаевфест”ны күтәрешергә җыелган республика җырчылары гына да 15ләп булды.

– Яратам шул егетне, ничек инде аның соравын кире кагып була, халкы өчен бәйрәм үткәрә бит ул,–ди Татарстанның халык артисткасы Хәмдүнә Тимергалиева. Юкса, аның бәйрәм графигы республика районнарыннан тыш Коми якларына, Рим, Красноярский кебек ерак нокталарга сәфәрләр белән бик тыгыз икән! Бәйрәмдә район башлыгы Равил Кузюров исеменнән котлау һәм Фирдүскә рәхмәт хаты тапшырган район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова бәйрәмнең масштаблылыгына басым ясап, якташыбызның үз халкына булган ихтирамын үрнәк итеп куйды.

– Фирдүс Нурлат исемен Россия сәхнәләреннән генә яңгыратмады, үз халкын яратуын бүгенге игелекле эше–бәйрәм бүләк итүе белән дә раслады,–диде ул. Соңрак бәйрәмгә килгән район башлыгы Равил Кузюров та Фирдүс Тямаевның бу игелекле гамәленә зур бәя бирде.

– Традициянең дәвамлы булуы сезнең үзегездән дә тора, – диде ул халыкка мөрәҗәгать итеп.

Бәйрәм бүләкләргә дә юмарт булды. Микрорайонның танылган кешеләрен, юбилярларны бүләкләү дисеңме, бәйрәмгә әзерлектә хезмәт куйган егетләрне билгеләүме, һәр төр ярышта катнашып җиңгән якташларга истәлек калдыруму–сәхнә алдын тутырган күчтәнәчләр ияләрен таба торды. Ат чабышында җиңүче Руслан Ибәтуллин, әтәчне эләктергән Рәсим Бакиров, көрәштә абсолют батыр Ленар Әхмәтшин көн геройлары булдылар. Бу көнне мәйданга чыгарга теләп республиканың дистәләп районыннан көрәшчеләр җыелган иде. Шулай да кунаклар арасында җиңүче титулын үзебезнең Илфат Гыймадиев читкә җибәрмичә, тәкәне үзебездә калдырды.




Җиңүчеләргә бүләкләрне район башлыгы үзе кул кысып тапшырды.

Мәйданда берничә урында барган бәйге, сәхнәдә берсен-берсе алыштырып торган җырчылар, аларга кушылып биюләр, сәүдә рәтләре, очрашу-күрешүләр һәм яхшы режиссер кебек боларның барысын да җылы юморы белән бергә туплап торган Фирдүс Тямаев. Аңардагы энергетика мәйданны көне буе бер йодрыкта тотарга, бәйрәмнең һәр бизәген ачарга булышты да бугай.

– Каян көч ала бу егет. Әле бит кичә энесенең туен да үткәрделәр, күпме кунак каршы алдылар, – диештеләр Тямаевлар гаиләсен якыннан белүчеләр.

– Түбән Нурлат бәхетле: исеме җырга керде, әледән-әле бәйрәме булып тора, – диде шушы авыл килене Миннегөл Әбҗәпбарова.

– Фирдүс белән эшләү дә, аңа пародия ясау да рәхәт: харизмасы көчле, халык аны ихлас ярата,–диде сәхнәдән яңа гына Фирдүсне сурәтләп төшкән Рифат Зарипов. Бәйрәм кичкә кадәр дәвам итте, киләсе елга кадәр, дип таралды күңеле булган халык. Икенче көнне исә барысы бергә әрәмәлекне чистартырга чыктылар. Ә Фирдүс якташларына тагы бер иҗади бүләк ясады: Нурлатта Балачак көнендә аның җырлавы нур өстенә нур булды.

**СҮЗ УҢАЕННАН...**

*Шулай да соңыннан Фирдүскә күп кешене кызыксындырган сорауны бирмичә кала алмадык: бәйрәм чыгымнары күпмегә басты?*

*– Нигә кирәк ул? Ярар, күңелләре булсын: 500 меңләп сумга төште. Минем өчен иң кыйммәте – халкыма матур бәйрәм ясый алдык, аны бернинди акча белән дә үлчәп булмый, – диде Фирдүс чын ир-егетләрчә.*

**Фотоларны nurlat-tat.ru сайтыннан карый аласыз.**

# Китапка күчкән нәсел язмышы

ГАИЛӘ УЧАГЫ




ЗУР ГАИЛӘ ҮЗӘГЕНДӘ – НАҖИЯ ХАНЫМ МАМЫШЕВА

**Узган шимбә көнне “Жизнь прожита не зря” китабын тәкъдир итү булды.**

Халкыбызда гыйбрәтле гомер юлы үткән кешеләр турында ”гомерләре китап язарлык”, дию гадәте бар. Нурлатлы Наҗия һәм Мобин Фәхриевлар тормышына, нәселенә багышланган “Жизнь прожита не зря” китабы белән танышкач исә: “Китап язар өчен шундый тормыш юлы үтү кирәктер,”– дигән уй туа. Шимбә көнне әлеге китапны тәкъдир итү кичәсенә җыелучылар чыгышында да шул ук фикер еш кабатланды. Ә “Яшьлек” ресторанына җыелган 70ләп кунак арасында Наҗия ханымның туган ягы Пензадан, Самара, Казан һ.б. шәһәрләрдән килгән туганнары, күпсанлы дуслары һәм хезмәттәшләре, гомер иткән күршеләре дә бар иде. Китап гаилә башлыгы Мобин ага Фәхриев һәм Наҗия ханым Мамышеваның шәҗәрәләреннән башланып китә һәм фотосурәтләр, язмалар, хатирәләр аша һәр ике нәсел язмышының иң гыйбрәтле вакыйгаларын бәян итә.

– Мобинемне югалткач, сагыштан-кайгыдан уйланып утырыр вакыт артты,–ди Наҗия ханым. – Шул вакытта минем уйларымны сизгәндәй, улым Илшат нәселебез турында туплаган материалларымны, истәлекләремне китап итеп чыгарырга тәкъдим итте. Рәхмәт аңа, һәм шунда ук Ходай юлыбызга Роза Вәлиәхмәтовнаны да очратты. Аның ярдәме һәм тырышлыгы белән китабыбыз дөньяга туды да.

Туганнар, балалар, оныкларны берләштереп торучы төп фигура – Наҗия ханым. Әле дә чибәр, көчле рухлы, шаян холыклы, сәләтле, аралашучан, ярдәмчел – китапта да, тәкъдир итү барышында да ул шундый булып ачылды.14 яшеннән мөстәкыйль тормышка баскан–Кыргызстанга китеп, Ош шәһәрендә педучилищега укырга кергән, соңрак институт бетергән кызның мамык җыйгандагы активлыгы ВЛКСМ ҮКның мактау грамотасы, Казахстанда төзелеш отряды составында чирәм җирләрне үзләштергәндәге хезмәте, укытучылык, директорлык иткәндәге уңышлары–һәммәсе дәрәҗәле бүләкләрен ала тора. Ике яшь йөрәк–Наҗия апа һәм Мобин аганың очрашуы да ерак Кыргызстанда була, иренең мәгариф юлына басуына да этәргечне Наҗия ханым бирә. Иренең туган ягына – Нурлатка кайткач да ул директор буларак төзелеш эшләреннән курыкмый, күп укучыларына югары белем алырга юл ача, кайда ярдәм кирәк–шунда аны күрсәтү җаен таба. Наҗия ханым – СССРның халык мәгарифе отличнигы, ә Мобин ага – ТРның атказанган укытучысы исеменә лаек булып, икесенә 100 елдан артык гомерләрен мәгариф тармагын үстерүгә багышлый гаилә. Гомере буе кайнанасы белән тату яшәп балаларына үрнәк күрсәткән Наҗия ханым һәм Мобин аганың балалары Роза, Рушания, Илшат та игелекле, кешеләргә игътибарлы булып үсәләр, тормышта үз лаеклы урыннарын табалар. Ә Наҗия ханымның тормыштагы иң зур бәхете–аның балалары, дөресрәге, аның үз балаларыннан ана буларак күргән хөрмәте. “Бу– минем тормышта күргән барлык авырлыкларыма язмышның бүләгедер,–ди Наҗия ханым үзе.–Балалар үз туган көннәрендә миңа чәчәк бәйләме бүләк итәләр. Алар мине инвалид арбасына утыртып Гарәп Әмирлегенә, Төркиягә, Италиягә алып бардылар. Һәр баламның иртәсе минем хәлемне белешүдән башлана.

Мөгаен, һәр ана кешенең иң зур хыялыдыр бу! Бай гомер юлының һәр тукталышы–үзенчә гыйбрәтле һәм кызыклы. Басманы төзүче-автор – ветеран-укытучы Роза Абдуллинаның йөгерек язу стиле һәм бай фактик материаллар аны гаилә ядкәре генә түгел, хәзинә булырлык гаилә китабы итә алган. Кичәне оештыру инициаторы –уллары Илшат Фәхриев үз кереш сүзендә аны шулай– тормыш китабы дип атады да. Тату, үз традициясе һәм әйтер сүзе, бүлешәсе нәтиҗәләре булган нәселдә генә туа ала мондый китап. Видеоязмалар, җылы чыгышлар, матур җырлар белән үрелеп барган тәкъдир итү кичәсе яшь дәвам өчен генә түгел, катнашучыларның барысы өчен дә уйландырырлык зур тәрбияви чара булды. Гаилә, нәсел дигән төшенчәләрнең кадерен белгән кеше генә тормышны да ярата. Наҗия ханым күзләрендә әле дә сүнмәгән яшьләрчә очкынның сере әнә шунда да!

**ЯЗМАЛАРНЫ СӘКИНӘ ХӘЙРУЛЛИНА ӘЗЕРЛӘДЕ**

# ВАКЫТ. ВАКЫЙГА

ТОРМЫШ. ЯШӘЕШ

## Солдатка китә оныклар

**Бу язда Яр Чаллы шәһәрендә яшәүче улымның ике малае да армиягә чакыру алдылар.**

– Баралар, безнең нәселдә армия хезмәтеннән калган ир-ат юк,–диде безгә хәбәр җиткергән әтиләре Илһам. Уйга калдым. Чыннан да, безнең Минаповлар гына да илгә күпме солдат үстергәннәр икән бит! Исәпне кайнатам Имамнан башлап санап китәм. Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югалган ул. Энесе Шәриф Ленинград блокадасында үлгән. Әтисен ничек сагынып көтүләрен искә алганда, иптәшем Әкрамның күзләрен еш кына яшь баса. 6 бала белән тол калган кайнанамның сабырлыгына, киң күңеллелегенә, тормышны яратуына гомер буе сокланып яшәдем. Ялгыз канат 4 улын исәнсау, акыллы, тормышны җигелеп тартырлык ир-егетләр итеп үстерә алган. Дүртесе дә ил алдындагы бурычларын үтәп, армия хезмәтен узганнар. Хәер, ул чакта армиягә бару дәрәҗә санала иде әле, улларыбыз шуны тоеп үстеләр. Солдат яшенә җиткәч, өчесе дә һич баш тартмыйча армиягә киттеләр, бер дигән итеп хезмәт итеп кайттылар. Улларымны мактап командирларыннан килгән хатларны әле дә кадерләп саклыйм. Илһамыбызга Әфган җирендә хезмәт итәргә туры килде. Ут йотып торган ул көннәрдә улыбызның бернинди зарланусыз, тынычландырып язган хатлары ата-ана өчен иң зур терәк булды. Шөкер, исәнсау кайтып, киленебез Руфия белән армиягә барырлык ике пәһлевандай ул үстерделәр. Онкыларым Илназ да, Рияз да авылны яратып, йорт хезмәтен белеп, тырыш булып үстеләр. Берсе институт, икенчесе техникум тәмамлап, инде ил алдындагы изге бурычларын үтәргә китәчәкләр.

Бурыч, васыять дигән нәрсәләр бездә гел изге төшенчә саналды шул. Кайнатамның әтисе Минап бабай заманында әтиебезгә:

– Улым, нигезебезне ташлама,–дигән булган. Шул сүз аны ерак Чиләбедән авылга кайтырга мәҗбүр иткән дә. Дөрестән дә, без төп нигездә яшәп калдык, шунда 6 ел әбине тәрбияләп соңгы юлга озаттык. Картайган көннәрендә 5 бала үстергән үз әти-әниемә дә безнең нигездә урын табылды. Догаларын алып, тәрбия биреп, бакыйлыкка озаттык.

–Мине бабайның догасы бәхетле итте,–дип еш кабатлый җәмәгатем. Алты туганыннан берүзе исән-сау ул бүген, балаларыбыз урнашкан, гаиләләре тату, 10 оныгыбыз, 2 оныкчыгыбыз үсеп килә. Заманалар үзгәрде бит, бер оныгыбыз Америкада яшәп ята, анда оныкчыгыбыз үсә. Шөкер, төп йортыбызда да тормыш сүнмәскә охшый, улыбыз Рафис һәм киленебез Гөлсинә, оныкларыбыз Рәшит һәм Гөлфия белән дөньябыз түгәрәк. Улыбыз бик акыллы Нәбиуллиннар нәселе белән кушылганнан бирле туганнарыбыз тагы да артты: һәр зур эшне кода-кодагыйлар белән бергәләшеп башкарабыз, шатлык булса да, борчу туса да ураклашып яшибез. Безнең йорт бүген Яр Чаллы, Башкортостан, Волгоград, ерак Себердә, Казанда, Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә яшәүче ике як туганнарыбыз өчен дә төп нигез санала: бирегә кайталар, кунак булалар, туган яклары белән элемтә саклыйлар. Әнә шушы була да бит инде бәхетле нигез дигән нәрсә.

...Оныкларымның армиягә китү хәбәре әнә шулай хатирәләргә бирелергә мәҗбүр итте әле мине. Аларга җиткерәсе юл теләкләремне көнсә әллә ничә кабатлыйм.

–Улларым, нәсел йөзен кызартырлык булмагыз. Намуслы хезмәт итегез, исән-сау әйләнеп кайтыгыз, – димен. Солдат өчен иң зур теләк шул бит инде!

**Василәә МИНАПОВА, Иске Әмзә авылы**

АВЫЛДА

## Кизләүлеләр бәйрәм итте

**Җәйге каникулларның беренче көне кизләүлеләр өчен балалар сабантуе белән истә калды.**

Балалар Сабантуе дисәләр дә, бәйрәмгә әти-әниләр, әби-бабайлар һәм авыл халкы күпләп җыелган иде. Халыкара балаларны яклау көненә багышланган чараны авылның имам-хатыйбы Вазыйх ага Мостафин ачып җибәрде. Капчык белән сугышу, чүлмәк вату, көянтә белән су ташу, аркан тартышу, әтәчкә менү кебек ярышларда олысы-кечесе рәхәтләнеп көч сынаштылар. Иң җитез киленнәр дә ачыкланды: болар – Әлфия Уразгильдеева һәм Лена Кәбирова булды. Алар көянтә белән су ташу ярышында үз осталыкларын күрсәттеләр. Ә әтәч Марат Кәримовка эләкте. Көрәштә Илфат Галиев – I, Әлфис Рәхимов – II, Шәфкать Сәлахов III урыннарны алдылар. Моннан тыш, бәйрәмдә мәктәпнең уку һәм спорт алдынгылары да билгеләп үтелде. Ә аралашу бәйрәм концерты һәм мул табыннар белән дәвам итте.

Бәйрәм иганәчеләрсез булмый, әлбәттә. Монда мәктәп директоры Вәлияр Халитов, Гөлнара Билданова, Киекле авыл җирлеге башлыгы Рәфис Ганиев, мәчет картлары, Илшат Гыймалетдинов, Әсләм Кәбиров, Рифкать Рәхмәтуллин, Сәмигулла Зәйдуллин, Нәҗип Билданов, Әнәс Камалетдинов, Илфат Касыймов кебекләрнең ярдәмнәрен һәм тырышлыкларын билгеләп узу кирәктер.

**Зилия ӘКСАНОВА**

ЯҢАЛЫК

## Чүп өчен акча да бирәләр...

**Пластик шешәләр, кулланылган полиэтилен пакетлар, пыяла шешәләр бик тиздән чүплекләрдән юкка чыгарга охшаган.**

Эш шунда, районның экологы Рөстәм Ногманов инициативасы буенча авыл җирлекләрендә икенчел чималны кабул итү пунктлары оештырылды. Фома, Тәрнәс кебек авыл җирлекләрендә инде халык бу эшкә тартылды да.

– Һәр авыл җирлегендә бу эш өчен җаваплы кешене билгеләдек, чималны җыю урынын җиһазлауны авыл җирлекләре башлыклары кайгыртты, – ди Рөстәм Ногманов эш тәртибе турында. – Чималны кабул итүгә, исәп-хисап урында ук ясала. Аннан аларны җыеп, районнан читтә эшкәртүгә озатачакбыз.

Халык әлеге яңалыкны уңай кабул итсә дә, зур активлык әлегә күренми.

– Балаларның укуы тәмамлангач, бу эш җанланыр дип уйлыйбыз, – ди Фома авыл җирлеге башлыгы Рәшит Абдрахманов әлегә бернәчә кешенең генә чимал китерүен әйтеп. Бирердә чимал җыю эшен Флүсә Шәяхмәтова алып бара икән, алар буш почта бинасына тупланачак.

Әйткәнебезчә, әлегә өч төрле чимал җыю гына оештырылган, эш кузгалып китсә, кәгазь калдыклары да кабул итә башлаячаклар. Аннан инде бу эшне шәһәрдә булдыру турында да сүз алып барырга мөмкин булачак, ди Рөстәм Әнвәрович. Тормыш шуңа таба бара: ни дисәң дә , бердән, икенчел чимал кулланыш таба, икенчедән, кешегә аз булса да акча эшләү мөмкинлеге тудырыла.

**Сәкинә НУРУЛЛИНА**

ӘДӘБИЯТ ЕЛЫ

## Китап укыган кеше югалмас

**- Балалар күбрәк компьютер, телевизор янында бит хәзер. Китап укымыйлар, - дип сүзен башлады даими укучыбыз, дистә елдан артыграк Кизләү авылында китапханәче булып эшләгән Гөлсирә апа Усманова.**

Үзе гомере буена китаплардан аерылмаган, һәр яңа әсәрне башыннан азагына кадәр йотлыгып укырга күнеккән һәм шуларның геройлары өчен чын йөрәктән борчылып һәм шатланып яшәгән ханымның бу сүзләре йөрәк әрнүе белән әйтүе күренеп тора. Әнә, әбиләре янына бернәчә генә көнгә килеп торган оныклары да өйгә керү белән телевизор кабызырга, мультфильмнар карарга ашыга.

- Кызым, карале, бу китапта никадәр мәгънә бар, әнтәлеге нинди гыйбрәтле, дип мин аларга күбрәк китап укырга, телевизордан аерырга тырышам, - ди Гөлсирә Кәримовна.

Бүгенге көндә Нурлатта яшәсә дә, туган авылына еш кайта Гөлсирә апа һәм, әлбәттә инде, үзе эшләгән китапханәгә дә сугыла. Тик хәзер авылдашларының да китапханәгә сирәгрәк йөрүен билгеләп үтә.

- Ул елларда авыл халкы арасында да китап укырга яратучылар күп иде. Әле дә хәтерлим, Миля апа Измайлова мөмкинлегә чикле булганлыктан, китапханәгә үзе йөри алмый. Аңа китапларны өенә илтеп өлгертә алмый торган идем. Әнисе артыннан кызы Кадрия дә китап укып үсте. Хәзер Мәскәүдә яши, эшмәкәрлек белән шөгыльләнә, дип ишеттем. Бала чактан китап укып үскән кеше югалмый ул, - дип дәвам итә сүзен әңгәмәдәшем.

Авылда яшәүче начар күрүчеләрнең өйләренә йөреп китап укуларын да хәтерли әле элеккеге китапханәче. Ул чагында авылда андыйлар 6–7 кеше исәпләнә, Гөлсирә апаның дөнья яңалыкларын, әдәби әсәрләрне укуын йотлыгып тыңлап, чын йөрәктән рәхмәт әйтеп кала торган булалар алар. Матур әдәбият аларның караңгы төсләрдән торган тормышларына нинди дер бер яктылык өсти торган булган, күрәсең.

Китапханәгә Кизләү кызы, бала чагыннан каләм чарлап үскән, бүгенге көндә газетабыз каршында эшләп килә торган "Нурлы як" түгәрәге әгъзасы Илһамия Низамованың да еш йөрүен искә алды Гөлсирә апа.

- Илһамия китап укырга искиткеч ярата. Балачактан әнисе белән китапханәгә көн саен диярлек йөриләр иде, - ди ул. Кыз күңелендә шигърияткә мәхәббәт орлыклары тупл килүен дә беренче булып Гөлсирә апа күреп ала. Шигырь язу сәләте уяныу, тәүге каләм тибрәтүенең дә шаһиты була, кызның беренче шигырь дәфтәрләрен дә саклый әле ул. Китапханәче белән Илһамия арасындагы дуслык исә бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Илһамиянең шактый борылмалы тормыш юлында киңәш биреп, кирәк чакта канат куеп, күңелен күтәреп, һәр яңа шигыренә ихлас шатланып торучы да ул. Һәм менә Илһамиянең Казан Дәүләт университетына читтән торып укырга керүен ишеткәч тә иң күп сөенүчеләрдән булгандыр, мөгаен. Әдәби әсәрләр үрнәгендә үскән кешене тормыш сынаулары сындырырга тиеш түгел - китап укудан, шигырьләрдән тәм табып яши белгән Гөлсирә апа моңа ихлас күңелдән ышана. Һәм әле китап укуның замана яшьләре арасында да модага керәсенә өметләнә.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**




ГӨЛСИРӘ УСМАНОВА ГОМЕРЕ БУЕ КИТАПТАН АЕРЫЛМАГАН

# ТӨРЛЕ. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

ҖИҢҮГӘ 70 ЕЛ

## Сугыш урлаган балачак

**– Ул вакытларны бер дә сагынмыйм, - дип искә ала тыл ветераны Лира ханым Якупова үзенең сугыш чорына туры килгән яшьлек елларын.**

Хәер, бер ул гына түгел, ул чорның кыенлыкларын күргәннәрнең күбесе аларны коточкыч төш кебек хәтерли: рәхәтләнеп шаярыр, күңел ачар вакытта үсмерләргә олылар белән бер рәттән урак урырга, үгезләр җигәргә, урман кисәргә туры килгән бит.

– Шундый авыр вакытлар булса да, халык күңелен төшермәде - яшьләр аулак өйләргә дә җыелгалый иде, кырда исә хатын-кызлар җырлый-җырлый эшләде. Күрәсең, болар ил өстенә төшкән зур кайгыны беразга булса да оныттырып торгандыр, - дип искә ала ул һәм янә хатирәләргә бирелә. – Сугыш башланганда, мин 5нче сыйныфны гына тәмамлаган идем әле. Тумышы белән Кайбыч якларыннан булган әтием Мирза Галимовның Яңа Әлмәт авылында укытучы булып эшләгән чагы. Бала булсак та, укытучыбыз Людмила Степановна белән без – укучылар утауга, бәрәңге төбе өяргә йөрибез. Соңрак әтиебезне Мамыкка район газетасына баш редактор итеп күчерделәр, ә 1943тә сугышка алдылар. Без исә Октябрина авылына элегрәк яшәгән нигезебезгә кайтып төпләндек. Үсмер кызлар һәм малайлар хатын-кызларга ияреп Тимерлек кырына карабодай чабарга барганыбыз, анда атналар буена кырда кунып калып эшләвебезне яхшы хәтерлим әле. 44нең кышында үгезләр җигеп орлык артыннан 30 чакрым ераклыктагы Норлат станциясенә баруыбыз да истән чыга торган түгел. Яшьтәшләрем Зәйнәп Идрисова, Фатыйма, Әминә, Сәлимгәрәй Хәйруллин, Мансур Әдиатуллин, Миннәхмәт, Хәлиулла Төхвәтуллин, Хәбир, Салихлар хәтта үгезләр җигеп сабанга да чыктылар.

Үзе һәрчак партия һәм дәүләт эшендә булган әтиләре исә балаларының да белемле булуларын тели һәм нинди генә авыр елларда да укудан аерылуларына ирек куймый. Лира да 10 сыйныфны Норлатның 2нче мәктәбенә йөреп тәмамлый.

- Ял көннәрендә капчыкларыбызны асып җәяүләп Норлатка киләбез. Аякларда – чабата. Мәктәптә суык, шуңа да өлкән сыйныфлар Вишневая Поляна урманына җәяүләп утын әзерләргә барабыз, аркылы пычкы белән кисәбез, - дип дәвам итә әңгәмәдәшем. Мәктәпне тәмамлагач исә кыз Казанның медицина институтында белем ала, яшь белгеч булып Норлатка эшкә кайта. Соңрак Буага җибәрелеп, бар гомерен шунда бактериолог һөнәренә багышлый, озак вакытлар районның санитар-эпидемиологик станциясен җитәкли, бик күп бүләкләргә ия була. Моннан 7 еллап элек яңадан яшьлек еллары узган төбәгенә, Нурлатка - туганнары яшәгән шәһәргә кайтып төпләнгәннәр. Җиңүнең 70 еллыгы көннәрендә исә күңеле Россия, Татарстан һәм район җитәкчелегенең игътибар һәм хөрмәтләре өчен рәхмәт белән тулы тыл хезмәтчәненең.


Автор фотосы

- Бу көннәрдә яшьлек елларын тагы да ешрак искә алам. Октябрина авылында бергә үскән, хезмәт куйган дусларымның күбесе вафат инде. Кайберләре бәлки исәндер дә, - ди ул. Һәм җылы сүз белән искә алуы аларга дога булып барып ирешүен тели – сугыш ветераннары белән бергә тыл фронтында хезмәт куйган буынның да фидакарьлеге онытылырга тиеш түгел!

Лилия МӨБАРӘКШИНА

С 5 по 30 июня
В МАГАЗИНЕ
«INFINITI»*
СКИДКИ 20% НА ЧАСЫ.
В наличии настенные, напольные, настольные часы производства России, Кореи, Японии, Китая.
ТЦ «ШИФА», 2 этаж
с 9.00 до 20.00.
*«Инфинити».
Подробности у продавцов.
ООО «Бухгалтерские системы».

- ПРОФНАСТИЛ
- САЙДИНГ
- УТЕПЛИТЕЛЬ
- ДОБОРНЫ ЭЛЕМЕНТЫ.
ДОСТАВКА.
Выезд на замер – бесплатно.
Кредит АО «ОТП Банк».
Т.: 8-927-470-29-39,
8-987-409-27-06.
Универсальный рынок,
м-н «Инструмент-град».

***Уважаемые жители города Нурлат и Нурлатского района!***
Приглашаем вас посетить городскую баню №1 по ул. Советская, 177 по приемлемым ценам: **130 руб. с 1 человека, 100 рублей – пенсионеры, инвалиды, 70 рублей – дети с 3 до 7 лет, бесплатно – дети до 3 лет, участники и ветераны ВОВ.**

Совет Кульбаево-Марасинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан

**РЕШЕНИЕ**

5 июня 2015 года №118

**О внесении дополнений в Решение Совета поселения от 29.12.2014 г. №104 «О назначении местного референдума на территории Кульбаево-Марасинского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан»**

В соответствии с Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 12.02.2015 г. №85 «О внесении изменений в Порядок предоставления из бюджета Республики Татарстан иных межбюджетных трансфертов бюджетам муниципальных образований Республики Татарстан на решение вопросов местного значения, осуществляемое с привлечением средств самообложения граждан, утвержденный постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22.11.2013 N 909», Совет Кульбаево-Марасинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан,

**РЕШИЛ:**

1. Дополнить Решение Совета Кульбаево-Марасинского сельского поселения от 29.12.2014 г. №104 «О назначении местного референдума на территории Кульбаево-Марасинского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан», пунктом 5 следующего содержания:

«Установить объем прогнозируемых доходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в размере 95000 рублей.

Установить направление прогнозируемого распределения расходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в виде:

80000 рублей на финансирование работ на содержание дорог в границах населенных пунктов сельского поселения;

5000 рублей на финансирование работ на содержание уличного освещения;

10000 рублей на финансирование работ на содержание свалки твердых бытовых отходов и благоустройство кладбищ».

2. Опубликовать настоящее решение в районной газете «Дуслык» («Дружба», «Туслах») и разместить на официальном сайте Нурлатского муниципального района в сети Интернет.

3. Настоящее решение вступает в силу со дня его опубликования.

**Г.Ф.Сафина**
**ВРИО Председателя Совета Кульбаево-Марасинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

СДАЮТСЯ В АРЕНДУ
ОФИСНЫЕ И СКЛАДСКИЕ ПОМЕЩЕНИЯ.
ВОЗМОЖНЫ ВАРИАНТЫ.
ОТ 150 РУБ. ЗА 1 КВ.М.
8-927-246-49-07.

*БАВАРСКИЕ ОКНА*
Тепло и уют Вашего дома.
- Пластиковые окна, лоджии, двери;
- Металлические и межкомнатные двери;
- Арки
- Горизонтальные и вертикальные жалюзи;
- Автоматические ворота;
- ОСП, гипсокартон;
- Теплицы
- Натяжные потолки

СКИДКИ – 1000 руб. на КАЖДОЕ изделие *
МОСКИТНАЯ СЕТКА В ПОДАРОК
Кредит**
Доставка и выезд инженера по замеру по г.Нурлат осуществляется - БЕСПЛАТНО!
Наш адрес: г.Нурлат ул.Советская, 92.
Тел.89370085308, 89274136982, 2-04-68
*скидки действуют на пластиковые изделия в период с 01.06.15 по 30.06.15 г. Условия у продавцов. Организатор: ИП Чванова Л.Л.
**кредит предоставляется АО «ОТП Банк».
Реклама

ГАДӘТТӘН ТЫШ

## ПОДВАЛДА УТ ЧЫККАН

**3 июньдә Шашин урамындагы 27нче йортның подвалында ут чыга. 125нче янгын часте начальнигы Илһам Курамшин әйтүенчә, монда кеше факторы гаепле икән.**

– Йортта яшәүчеләрнең уяулыгы аркасында ялкын вакытында сүндерелде, – ди Илһам Исламович. – Әлеге йортның беренче катында яшәүчеләр төтен исен сизүгә безнең частька хәбәр бирделәр.

125нче янгын часте коткаручылары тиз арада вакыйга урынына чыга. Ут белән көрәшкә 73нче янгын часте да җәлеп ителә: төтен чамадан тыш күп чыкканлыктан, утны махсус киемнәр һәм чаралар ярдәмендә ликвидациялиләр. Йортта яшәүчеләрне оператив рәвештә эвакуациялиләр. Ашыгыч ярдәм, электр, газ службалары, участок уполномоченные да вакыйга урынына тиз арада килеп җитәләр. “Подвал үзе бикле булган, әмма кемнәрдер аны ватып эчкә үткәннәр, тәмәке тартудан яисә ут белән башкача саксыз эш итүдән андагы төзелеш калдыкларына ут капкан. Шөкер, халыкның уяулыгы, янгын сүндерүчеләрең оперативлыгы, башка службаларның көйле эшләве нәтиҗәсендә ялкынга артык үрләргә юл куелмады. Янгынның мәйданы 1 квадрат метрдан артмады”, – диде Илһам Курамшин. Шунда ук торак милекчеләре ширкәтләре җитәкчеләренең дә, халыкның да йортлардагы подвалларның, ярдәмче корылмаларның һәрчак бик астында булуын күз угыннан ычкындырмаска киңәш итте.

Илназ МӨБАРӘКШИН

МӘГАРИФ

### КАДЕТЛАР СӘЯХӘТТӘ

Атна дәвамында гимназиянең 8нче сыйныф укучылары – барлыгы 20 егет һәм кыз “Кадетлар туры” дип аталган экскурсион сәяхәттә. Укучылар теплоходта Казан, Ульян, Түбән Кама, Алабуга, Чистай шәһәрләренә, Зөя утравына сәяхәт кыла. Әлеге тур аларга ТР ДОСААФының Нурлат районы бүлеге аша оештырылган.

### ИМИНЛЕК МӘКТӘПТӘН БАШЛАНА

“Тормыш иминлеге нигезләре” курсын укучыларга өйрәтү буенча иң яхшы мәгариф учреждениесе район смотр-конкурсына нәтиҗәләр ясалды. 27–30 апрельдә узган конкурста барлыгы 28 мәктәп катнашкан. Нәтиҗәдә, Киекле урта мәктәбе – I, шәһәрнең 9нчы урта мәктәбе – II, Егоркино урта мәктәбе III урынга чыккан.

### РАЙОН ДАНЫН ЯКЛАДЫЛАР

ТР МЧСы һәм Мәгариф һәм фән министрлыгы үткәргән “Иминлек мәктәбе” республика ярышларында район данын шәһәрнең 3нче урта мәктәбе командасы (җитәкчеләре Юрий Пименев) яклады. Чара 18-22 майда Мамадыш районының Соколки торак пунктында узды. Шәһәрнең 3нче урта мәктәбе командасы мондый ярышларда икенче ел рәттән катнаша инде. Ярышларда команда әгъзалары экстремаль ситуацияләрдә эш итүгә өйрәнгән. Моннан тыш, нормативлар – ”каршылыклар полосасы”н тапшырганнар, беренче медицина ярдәме күрсәтү, альпинист күнекмәләре, спорт ярышларында катнашканнар.

– Тормыш иминлеге дәресләре һәркем өчен кирәкле фән, - ди район мәгариф бүлеге җитәкчесе Линар Маняпов. – Әмма тагын да тирәнрәк итеп аны өстәмә дәресләрдә өйрәнергә мөмкин. Шәһәрнең 3нче урта мәктәбендә бу юнәлештә җитди эш 2нче ел рәттән алып барыла. Һәм монда иң мөһиме – беренче ярдәм күрсәтә белү.

### ӘЗЕРЛЕККӘ МОНИТОРИНГ

Район мәгариф бүлегенең мәктәпкәчә белем бирү бүлеге хезмәткәрләре балаларның мәктәпкә әзерлеге буенча мониторинг үткәрделәр. Агымдагы елда балалар бакчаларыннан китәчәк 556 чыгарылышның 536сы тестлаштыруны уңышлы үткән. Районның балалар бакчаларына комплектлау эше 22 июньнән башланачак, дип хәбәр итәләр бүлектә.

### ПИТЕРДАГЫ УҢЫШ

Балалар сәнгать мәктәбенең “Баян” классы буенча 2 сыйныф укучысы Семен Леонтьев Санкт-Петербург шәһәрендә узган “Волшебная феерия” Халыкара фестиваль-конкурсыннан II дәрәҗә лауреат булып кайтты. Дәрәҗәле фестиваль 29–31 майда узган. Түбән Чаллы авылыннан Семен Леонтьев фестивальдә җитәкчесе – Балалар сәнгать мәктәбе укытучысы, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Тәлгать Бадыйгин белән катнашкан.

Зилия ӘКСАНОВА

# КОТЛАУЛАР. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА

## КОТЛЫЙБЫЗ!

**Бикколда** туып, хәзер **Нурлатта яшәүче** сеңлем, апабыз **Флера Миннехан кызы Фәйзуллинаны** алтын юбилее белән котлыйбыз. Аңа озын гомер, шатлык-сөенечләр белән тулы тигез тормыш телибез.

Котлыйбыз без туган
көнең белән,
Шау чәчәкле айда тугансың.
Шуңа күрәдерме ягымлы да,
Мәрхәмәтле, сабыр булгансың.
Бездән сиңа шушы изге теләк–
Борчуларсыз яшә гомергә.
Кайгы-хәсрәт күрми,
бәхет белән
Яшик әле алда гел бергә.

**Ихлас теләкләр белән Нуриҗановлар, Җамаловлар, Мөбарәкшиннар.**

Күршем, классташым һәм дустым **Флера Миннехан кызы Фәйзуллинаны** 50 яшьлек юбилее белән котлыйм. Аңа имин тормыш, тигез гомер телим.

Көнең үтсен бары
шатлык белән,
Юлларыңа гөлләр сибелсен.
Табигатьнең һәр иртәсе-таңы
Гомерлеккә бәхет китерсен.

**Бикколдан дустың Халидә.**

**Алсу Гаяз кызы Гафурованы** күркәм бәйрәме – 55 яшьлек юбилее белән котлыйбыз!

Олы йөрәкле сеңлебез-апабызга алдагы көннәрдә кайгы-хәсрәт күрми, балаларына таяныч булып, озын-озак яшәргә насыйп булсын.

Карашларың җылы
яңгыр кебек,
Елмаюың айдай сөйкемле,
Шәфкатеңнең иге-чиге юк бит,
Кояш чәчкән нурлар шикелле.
Ак бәхетләр юлдаш
булсын сиңа,
Көннәреңне шатлык бизәсен,
Сәламәтлек – үзе бәхет бит ул,
Ходай шуннан мәхрүм итмәсен.

**Иң изге теләкләр белән сине яратып әниең, апаларың, сеңелләрең, энеләрең.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!



**Киекле авылында** яшәүче туганнарыбыз **Нурисә Әнвәр кызы Ганиевага** 5 июньдә 50 яшь, **Әхәт Юныс улы Ганиевка** 6 июньдә 52 яшь тула. Кадерлеләребез, сезне туган көннәрегез белән котлыйбыз.

Киләчәктә сезгә тигез гомер, исәнлек телибез. Озын тормыш юлларын үткән чакта хисләрегез сүрелмәсен, канатларыгыз талмасын, бәхет-шатлыкларга күмелеп, һәр кешегә үрнәк булып, туган һәр көнгә сөенеп яшәгез.

**Изге теләкләр белән апагыз Люция, Ленар, Эльвира, Сәмирә, сеңлегез Нурия, Илфат, Илшат, Света, Ләйсән, Илнар, Әдилә, Әмилә, әтиегез һәм башка барлык туганнар.**

## РӘХМӘТЕБЕЗ ЧИКСЕЗ

**Иске Авылда** яшәгән кадерле әтиебез, тормыш иптәшем, яраткан туганыбыз **Васыйл Идрис улы Әхмәтсәгыйров** 75 яшендә кинәт вафат булды.

Кадерле әтиебезне соңгы юлга озатканда авыр кайгыбызны уртаклашкан, хәлебезгә кереп, матди һәм рухи яктан ярдәм иткән барлык авылдашларга, туганнарга, күршеләребезгә, Нурлат шәһәре һәм бөтен авыл мәчетләрендә эшләүче бабайларга аеруча зур рәхмәтебезне белдерәбез. Әтиебез иң изге кешеләрдән иде. Без сине мәңге онытмыйбыз, сине яратып яшибез.

**Тормыш иптәше, балалары, барлык туганнары, киленнәре, кияүләре.**

12+ "ТНТ-Нурлат" тәкъдим итә

**8 ИЮНЬ**
Музыкаль тапшыру, чуваш телендә.

**10 ИЮНЬ**
"Нурлат хәбәрләре",
"Татнефть" хәбәрләре.

**12 ИЮНЬ**
"Нурлат хәбәрләре".
"Сиңа дигән җырым", музыкаль тапшыру

Программалар **19** сәгатьтә башлана. **9, 11, 13 июньдә** иртәнге **7дә** кабатлап күрсәтелә.

**САБАНТУЙГА КИЛЕГЕЗ!**

**7 ИЮНЬ КӨННЕ БАРЛЫК АВЫЛДАШЛАРНЫ, КИЕКЛЕ, ҮРНӘК АВЫЛЫ ХАЛКЫН, РАЙОНДАШЛАРНЫ ҺӘМ ШӘҺӘР КУНАКЛАРЫН 10.00 СӘГАТЬТӘ КИЗЛӘҮ САБАНТУЕНДА КӨТЕП КАЛАБЫЗ!**

## НЕДВИЖИМОСТЬ

.*участок под гараж (фундамент). Т. 8-927-677-51-78. П/с №16-16-35/016-2013-574.

*дом (д. Средняя Камышла, ул. Школьная, 66) или обменивается на 1-комнатную квартиру в Нурлате.

*2-комнатная квартира, ремонт, 4 этаж, мкр. Яшлек. Т. 8-937-599-20-45.

*новый дом, мкр. Северо-Восточный. Т. 8-929-729-44-46.

*дом с. Егоркино. Т. 8-927-419-36-51.

*2-комнатная квартира, центр. Т. 8-927-450-16-85.

*дом с. Тюрнясево. Т. 8-927-435-12-10.

*3-комнатная квартира, центр. Т. 8-937-580-20-79.

*старый дом с участком. Т. 8-927-679-58-67.

*дом, ж/д. Цена договорная. Т. 8-929-72-30-066.

*дома: ул. Кутузова, ул. Ипподромная (недострой), ул. Тукая, ул. Юбилейная, с. Курманаево. Т. 8-929-727-12-82.

*1-комнатная квартира, с/з, 2 этаж. Т. 8-927-431-48-29.

**3-комнатная квартира, 120 кв.м, ул. Кариева, 6. Т. 8-927-037-60-04.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*1-комнатная квартира, г. Казань. Т. 8-927-440-40-54.

*дом, ул. Советская, 117. Т. 8-927-243-65-08.

*2-комнатная квартира в центре, 40 кв.м, 1 млн. руб. Т. 8-927-243-83-30.

*3-комнатная квартира, ул. Кариева. Т. 8-927-457-40-44.

*1-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 500000, торг. Т.: 8-927-245-66-78, 8-927-403-91-42.

*дом. Варианты. Т. 8-937-283-86-00.

*дом на ж/д. Т. 8-927-414-73-53.

*магазин на продуктовом рынке. Т. 8-927-049-26-51.

*гараж, ул. Линейная, 63. Т. 8-927-247-09-89.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, 60 кв.м, индивидуальное отопление, 1430000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Кариева, 1 этаж, 50 кв.м, 1,3 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*дом по ул. Декабристов, 49. Т. 2-87-36.

*дом, мкр. Нижний Нурлат, ул. Рощевая, д. 29. Т. 8-927-436-80-97.

*1-комнатная квартира в 5-этажном доме, 3 этаж, около центрального рынка. Т. 8-927-458-33-72.

*земельный участок, ул. Маслозаводская, 17, 5 соток, 220 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70. П/с 16-56.-10.3-549.1

*3-комнатная квартира, гараж. Т. 8-927-450-82-22.

*деревянный дом в д. Светлое Озеро на разбор и вывоз. Т. 8-927-402-75-09.

***2-комнатные квартиры**, ул. Сайдашева, ул. Заводская, дом, ул. Михеева. Т. 8-937-77-40-132.

*дом, ул. Гиматдинова, 146. Т. 8-9274-222-441.

*срочно комната. Т. 8-927-047-10-21.

***2-комнатная квартира,** ул. Гиматдинова, 80, 1100000 руб.; **2-комнатная квартира**, ул. Гагарина, 2, 880000 руб., торг; **2-комнатная квартира** с ремонтом, ул. Советская, 195, 1030000 руб. Т. 8-929-727-12-82 (Ксения).

*2-комнатная квартира, ул. Кариева, с мебелью, рядом с мечетью. Т.: 2-97-60, 8-917-230-93-97.

***1-комнатная квартира в Самаре, 2 этаж, 5ти этажного дома по ул. Гагарина, ст. метро Спортивная. Т. 8-927-757-07-46.**

## АВТОТРАНСПОРТ

*«Нива-212140», пробег 27000, 1 хозяин, отличное состояние. Т. 8-952-046-02-31.

*трактор «МТЗ-80», 1994 г/в; «МТЗ-80», 1989 г/в; плуг 2-корпусный. Т. 8-937-583-46-16.

*«ВАЗ-2107», 2002 г/в. Т. 8-927-457-99-61.

*трактор «Т-40». Т. 8-987-187-64-53.

*«Лада Калина 111830», серебристый седан, комплектация норма, 185000 руб. Т. 8-927-445-04-57.

*«ВАЗ-21099», 2001 г/в, на ходу, дешево. Т. 8-927-441-81-61.

*«УАЗ-4696», 2008 г/в, полный капремонт, 150000. Т. 8-952-046-02-31.

*«ВАЗ-21154», в хорошем состоянии, 2008 г/в. Т. 8-927-458-17-84.

*«ИЖ-2126030», 2002 г/в. Т. 2-84-11.

*«Дэу Матиз», 2008 г/в, АКП. Т. 8-987-060-60-03.

*«УАЗ» бортовой, 2002 г/в. Т. 8-937-529-32-68.

*«Рено Логан», 2007 г/в. Т. 8-927-243-28-09.

*«ВАЗ-21099», 1999 г/в, в нормальном состоянии. Т. 8-927-413-15-99.

*«Приора», 2013 г/в, норма+, цвет «космос», автозапуск, магнитола, резина зима-лето, литье, ПТФ ксенон. Т. 8-937-523-60-06.

## ДРУГОЕ

*ШИКӘР КОМЫ-2250, ОН-970, «Юмарт» кибете. Т. 8-927-445-68-55.

*куры-молодки, бройлеры, несушки, утки, гуси. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.

*бычки (молодняк) от 2 до 5 месяцев. Т. 8-927-870-58-98.

*телята, молодняк. Т. 8-927-987-87-63.

*доски осина, сосна, брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*утки, гуси, молодки, бройлеры. Доставка. Т.: 8-937-286-57-23, 8-937-621-81-57.

*реализуем 1-, 2-месячных: индейка HybridConverter, гусята, утята муларды, бройлеры в пгт. Алексеевское. Т.: 8-905-020-83-38, 8-905-345-79-70.

*бычки (молодняк). Т. 8-927-870-49-62.

*бут, ПГС, песок, перегной. Т.: 8-927-248-19-66, 8-937-248-21-66.

*семена – костер, люцерна. Т. 8-927-470-39-02.

*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-917-936-04-05.

*вощина ульяновская, 420 руб./кг. Обмен на воск. Т. 8-927-751-61-46.

*кухонный стол (1,50х90), стулья, прихожая 1,65, кровать 1,5, письменный стол, б/у. Т. 8-929-727-09-58.

**ТРУБЫ НКТ.
Нарезаем по размерам.
8-937-288-42-67,
8-987-239-14-54.**

*овцы. Т. 8-927-67-36-249.

*ПГС, бут, песок. Т. 8-927-247-27-37.

*песок, ПГС, бут, щебень, цемент, чернозем. Т. 8-927-247-94-76.

*овцы. Т. 8-927-673-82-45.

*говядина, молодняк по частям и кусками; бычок 1 год. Т. 8-927-245-32-03.

*корова, 2 отела. Т. 8-917-299-82-89.

*керамзит, керамблоки. Т. 8-927-247-85-89.

*фундаментные блоки, плиты перекрытия, кирпич, б/у. Т. 8-960-822-72-75.

*срочно емкость, 6 куб. Т. 8-937-526-44-04.

*подрощенные утята, мулларды. Т.: 4-35-11, 8-927-422-92-58.

*памперсы для взрослых. Т. 8-917-863-71-60.

*мотоблок «Урал» с тележкой. Т. 8-927-673-06-03.

*кухонный уголок, стол журнальный, пальто демисезонное, костюм мужской, недорого. Т. 8-927-247-07-22

КАМЫШЛИНСКИЙ ИНКУБАТОР ПРИНИМАЕТ ЗАЯВКУ НА СУТОЧНЫХ БРОЙЛЕРОВ, УТЯТ, ГУСЯТ, ИНДЮШАТ.
**4-35-47, 8-937-620-80-30 (Румия).**

*поросята. Т. 8-937-610-60-72.

*ПГС, песок, «КамАЗ», 15 тонн. Т. 8-927-454-61-01.

*овцы (9 мес.). Т. 8-927-426-36-29.

*телевизор «Томсон», диагональ 71, 3500. Т. 8-927-471-13-04.

*кролики (самки), крольчата. Т. 8-927-409-76-18.

*чернозем, перегной. Т. 8-927-463-63-17.

## РАЗНОЕ

*Йомшак җиһаз тарттыру, ремонтлау. Т. 8-937-570-60-21.

*Йөк күчерү, «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*ремонт холодильников. Т.: 2-71-69, 8-937-610-58-78.

*копаем, чистим колодцы, копаем фундаменты (вручную). Т.: 8-929-723-88-60, 8-937-528-80-32, 8-986-711-25-32.

*услуги сварщика (любой сложности). Т. 8-937-004-40-78.

*все виды отделочных работ. Качественно, недорого. Т. 8-937-773-98-04.

*татуаж, макиаж, маникюр, педикюр, шугаринг. Т . 8-927-402-25-12.

*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.

*ремонт, настройка компьютеров, Wi-Fi, Интернета. Выезд. Т. 8-937-0051-451.

*замена электропроводки. Т. 8-929-728-93-36.

*грузоперевозки, «ГАЗель». Т. 8-937-570-54-75.

*ремонт пластиковых окон, москитных сеток. Т. 8-927-249-54-24.

*установка окон, дверей, откосов. Т.: 8-927-671-26-59, 8-987-189-59-02.

*манипулятор. Т. 8-929-721-79-77.

***кузовной ремонт. Т. 8-917-865-30-35.**

*шпаклевка, поклейка обоев, недорого. Т. 8-929-726-83-76.

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.

## ТРЕБУЕТСЯ

*парикмахеры. Т. 8-927-403-91-39.

*парикмахер. Т. 8-927-421-80-33.

*массажист. Т.: 2-43-03, 2-43-04.

*электромонтер. Т. 8-917-398-26-41.

*в ООО «Центр Сервисных Услуг» токари с опытом работы на трубо-нарезных станках с ЧПУ типа РТ772 и РТ783 (без ЧПУ). с.Мамыково, ул. Тельмана, 45. Т. 97-652.

*повар. Т. 8-927-427-79-97.

## КУПЛЮ

*Алгы приводлы «ВАЗ»лар, чит ил машиналары. Кыйммәткә. Т. 8-927-456-00-07.


*КЫЙММӘТКӘ АВТО САТЫП АЛАМ. Т. 8-937-588-36-46.

*Мөгезле эре терлек, эре терлек тиреләре. Кыйммәткә. Т. 8-927-412-29-99.

*пух-перо утиное, гусиное. Старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.

*баллоны кислородные, углекислотные. Т. 8-987-292-01-10. ООО «ГК «Втормет».

**СТЕНОВЫЕ БЛОКИ**
400х200х200 – 40 руб.
400х200х120 – 32 руб.
Используются для строительства домов, бань, сараев, гаражей.
Доставка от 1080 шт. по г.Нурлат и Нурлатскому району бесплатно.
8-902-337-19-37, 8-848-250-01-70.




Реклама

*2-комнатную квартиру с ремонтом, ж/д, с/з, 1,5 этажи не предлагать. Т. 8-927-434-17-84.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

## СДАЮТСЯ

*квартира посуточно, ул. Вахитова. Т. 8-927-247-00-80.

*гараж в аренду по ул. Самаренкина, свет подключен (380V). Т. 8-927-419-56-02.

*в парикмахерской рабочие места. Т. 8-937-287-68-88.

*квартира посуточно, командировочным. Т. 8-927-456-05-69.

*1-комнатная квартира. Т. 2-93-44.

*новая 1-комнатная квартира в г. Альметьевск, 6000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

## ПОТЕРИ

*утеряна зачетная книжка №614147 на имя Гульназ Шаукатовны Валиуллиной.

**Совет Новотумбинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

**РЕШЕНИЕ**

от 18 мая 2015 года №91

**О внесении дополнений в Решение Совета поселения от 14.01.2015 г. №81 «О назначении местного референдума на территории Новотумбинского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан»**

В соответствии с Постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 12.02.2015 г. №85 «О внесении изменений в Порядок предоставления из бюджета Республики Татарстан иных межбюджетных трансфертов бюджетам муниципальных образований Республики Татарстан на решение вопросов местного значения, осуществляемое с привлечением средств самообложения граждан, утвержденный постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 22.11.2013 N 909», Совет Новотумбинского сельского поселения Нурлатского муниципального района Республики Татарстан,

**РЕШИЛ:**

1. Дополнить Решение Совета Новотумбинского сельского поселения от 14.01.2015 г. №81 «О назначении местного референдума на территории Новотумбинского сельского поселения по вопросу введения и использования средств самообложения граждан», пунктом 5 следующего содержания:

«Установить объем прогнозируемых доходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в размере 33500 рублей.

Установить направление прогнозируемого распределения расходов от средств собранных по результатам проведенного самообложения граждан в виде:

3500 рублей на финансирование работ на ремонт внутрипоселенческих дорог;

30000 рублей на финансирование работ на содержание кладбищ».

2. Опубликовать настоящее решение в районной газете «Дружба» («Дуслык», «Туслах») и разместить на официальном сайте Нурлатского муниципального района в сети Интернет.

3. Настоящее решение вступает в силу со дня его опубликования.

**Л.Н.Осипов
Председатель Совета
Новотумбинского сельского поселения
Нурлатского муниципального района Республики Татарстан**

